Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының кырык икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы
КАРАРЫ

22 май, 2024 ел № 326

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең 2024 елның 8 апрелендәге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында» 2015 елның 13 августындагы 15 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга (2016 елның 12 гыйнварындагы 35 номерлы, 2020 елның 21 маендагы 148 номерлы үзгәрешләр белән).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
башлыгы урынбасары В.А. Игнатьева